КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 март г.Казань № 187

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 сентябрь, 875 нче; 2019 ел, 15 май, 397 нче; 2021 ел, 19 апрель, 256 нчы; 2021 ел, 5 июль, 544 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидия бирү Министрлык һәм Фонд арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә.»;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ – $11^3$ пунктлар өстәргә:

«$11^1$. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше;

субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

субсидияне күчерү сроклары һәм тәртибе;

Фонд тарафыннан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап, өстәмә хисаплылык кертү сроклары һәм формалары;

Субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар Фонд тарафыннан бозылган, шул исәптән аларның бозылуы Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракта, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидияне кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

бу Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләре;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда әлеге акчага ихтыяҗ булу яки әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда аларны кире кайтару турында карар кабул ителгәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган шарт;

Фондның һәм Фонд белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан аларның субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүне гамәлгә ашыруга карата ризалыгы;

Фонд, шулай ук Фонд белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен субсидия алганда);

Фонд тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү хакында шарт;

$11^2$. Министрлык һәм Фонд, кирәк булуга карап, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган, килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

$11^3$. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

бу Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җаваплылыкны үз өстенә алып бирелгән сумма 100 процент бирелгән субсидия күләмендә;

бу Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чараларны тормышка ашырганда – үткәрелгән чаралар саны – 14 берәмлек.

Бу пунктта күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

13 пунктта:

«а» пунктчасының өченче абзацында «ирешү турында хисап» сүзләре алдына «мәгънәләренә» сүзен өстәргә;

«б» пунктчасының икенче абзацында «ирешү турында хисап» сүзләре алдына «мәгънәләренә» сүзен өстәргә;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы Фондка субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнар белән билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.».

2. Бу карар (2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның егерме сигезенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин